Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомбыт авыл җирлеге составына керүче
Шестая Речка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

20 ноябрь 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 20 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең Шестая Речка авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 1000 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- авыл җирлеге чикләрендә юлларны кышка карап тоту һәм ремонтлау;
- авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын тоту (су челтәрләрен ремонтлау, тирән насослар сатып алу););
- авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (пирс төзелеше, янгын сүндерү гидрантлары, янгын җиңсәләре, күрсәткечләр сатып алу);
- Шомбыт, Шестая Речка, Камский, Степановка торак пунктларында энергия саклаучы яктырткычлар һәм аларга комплектлау өлешләре сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау;
- авыл җирлеге чикләрендә чүп үләннәрен чабу.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 117 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 62 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 62 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге составына керүче Шестая Речка авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез  2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы  Шомбыт авыл җирлегенең  Шестая Речка авыл торак пунктында  тору урыны буенча  теркәлгән  балигъ  булган  һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре)  1000 сум күләмендә үзара салым  акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны  җирле әһәмияттәге  мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- авыл җирлеге чикләрендә юлларны кышка карап тоту һәм ремонтлау;

- авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын тоту (су челтәрләрен ремонтлау, тирән насослар сатып алу););

- авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (пирс төзелеше, янгын сүндерү гидрантлары, янгын җиңсәләре, күрсәткечләр сатып алу);

- Шомбыт, Шестая Речка, Камский, Степановка торак пунктларында энергия саклаучы яктырткычлар һәм аларга комплектлау өлешләре сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау;

- авыл җирлеге чикләрендә чүп үләннәрен чабу.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат  стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомбыт авылы, Совет урамы, 18 йорт;Шомбыт авылы, Завод урамы, 22 йорт;Шестая Речка авылы,  Лесная урамы, 6 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Сергеев Н.Е.

Шомбыт авыл җирлеге башлыгы: Сергеев Н.Е.